ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«31» март 2023 ел № 399

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 3 мартындагы 126 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.10.2019 № 979 карары белән расланган "Аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы башкара торган Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура- спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында" 2021 елның 03 июлендәге 537 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура- спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында" Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 3 мартындагы 126 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карарның 1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 2 510 сум күләмендә, әмма аена 2 510 сумнан артмый;»;

2) "Аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Арча муниципаль районы Башкарма комитеты башкара торган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура- спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләү бирү тәртибе" дигән 1 нче кушымтада:

2.1) 1 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 2 510 сум күләмендә, әмма аена 2 510 сумнан артмый.»;

2.2) 3 пунктта 30 яшькә кадәр сүзләрен 35 яшькә кадәр сүзләр белән алыштырырга;

2.3) 9 нчы пунктта "Р - хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү 1 111 сум күләмендә" дигән сүзләрне «Р-хезмәткәрләргә -яшь белгечләргә стимуллаштыручы өстәмә түләү 2510 сум күләмендә" дигән сүзләр белән алыштырырга;";

3) "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура -спорт оешмалары хезмәткәрләренә субсидия бирү турында килешү формасы" дигән 2 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo/tatarstan/ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http://arsk/tatarstan/ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р. М. Гатиятов

Татарстан Республикасы спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль берәмлеге арасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура -спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләргә акчалата түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Арча муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү

Казан ш. «____» ________2023ел

Алга таба «Министрлык» дип аталачак Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы исеменнән Нигезләмә нигезендә эш итүче министр В. А. Леонов бер яктан, һәм, алга таба «Алучы» дип аталачак Татарстан Республикасы Арча муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән Нигезләмә нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Арча муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Р. М. Гатиятов икенче яктан, алга таба бергә «Яклар» дип аталачак, «2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура- спорт оешмалары хезмәткәрләренә-яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешүнең предметы булып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура- спорт оешмалары хезмәткәрләренә-яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» 31.10.2019 № 979 карары нигезендә 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура- спорт оешмалары яшь белгечләренә акчалата түләүләр бирү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тора.

1.2. Әлеге Килешүдә каралган максатларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирелә.

1.3. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль берәмлеге бюджетына спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура- спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләргә акчалата түләү өчен бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме Арча муниципаль берәмлеге тарафыннан ай саен бирелә торган гаризалар нигезендә билгеләнә.

## 2. Якларның вәкаләтләре

2.1. Министрлык:

2023 елда «Татарстан Республикасы спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының хезмәткәрләренә-яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.10.2019 №979 карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль берәмлеге бюджетына эшчеләргә-яшь белгечләргә акчалата түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирүне тәэмин итә, аерым алганда Министрлык финанслауның чик күләмнәре күрсәтелгән максатларга җиткерелгәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын исәпкә алу өчен Россия Банкының исәп-хисап челтәре бүлекчәләрендә ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе хисап счетына башка бюджетара трансфертлар күчерә.

2.1.1. Әлеге Килешү кысаларында алынган башка бюджетара трансфертларны биргәндә билгеләнгән шартларның үтәлешен, шул исәптән башка бюджетара трансфертларны максатчан куллануны контрольдә тота.

2.1.2. Түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгына Алучыга башка бюджетара трансфертлар бирүне туктатып тору турында тәкъдимнәр җибәрә:

Алучының башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозуы, шулай ук аның чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә түләүгә бирелгән башка бюджетара трансфертлар торган Татарстан Республикасы Арча муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында айлык хисап бирмәве.

2.2. Алучы:

2.2.1. «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура -спорт оешмалары хезмәткәрләренә-яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.10.2019 №979 карарына ярашлы рәвештә спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура- спорт оешмаларын финанслый.

2.2.2.Министрлык боерыгы белән расланган форма буенчаТатарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура -спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләр реестрын алып бара һәм ай саен, агымдагы айның 5 нче көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка башка бюджетара трансфертлар бирү өчен реестр һәм гариза тапшыра.

2.2.3.Хисаптан соңгы айның 15 нче көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка финанс тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларының чыгымнары һәм әлеге килешүгә 1 нче кушымта нигезендәге форма һәм тәртип буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында хисаплар тапшыра.

2.2.4.Башка бюджетара трансфертларны куллану нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткече (нәтиҗәсе) булып тиешле финанс елына спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура -спорт оешмаларында алынган белгечлек профиле буенча эшләүче һөнәри белем бирү оешмаларын яки физкультура - спорт юнәлешендәге югары белем бирү оешмаларын тәмамлаган хезмәткәрләрнең-яшь белгечләрнең исемлек буенча уртача саны тора.

2.2.5.Агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне дәвамында, бюджет законнары нигезендә, муниципаль районның күрсәтелгән субсидиягә ихтыяҗы булмаганда, файдаланылмаган субсидия калдыгын Татарстан Республикасы бюджеты керемена кайтаруны гамәлгә ашыра.

2.2.6.Министрлык таләбе буенча әлеге Килешү кысаларында алынган башка бюджетара трансфертларны куллану белән бәйле бухгалтерлык исәп-хисабы мәгълүматларын тапшыра.

2.3. Башка бюджетара трансферларны максатсыз куллану, аларны тулы күләмдә кулланмау очракларында Килешүне өзү килешү белән рәсмиләштерелә һәм ике яклы тәртиптә имзалана.

### 3. Якларның җаваплылыгы

3.1. Әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

3.2. Алучы әлеге Килешүдә билгеләнгән максатлар нигезендә башка бюджетара трансфертларны бирү һәм куллану шартларын үтәмәү, әлеге Килешүнең 2.2.3, 2.2.5 пунктларында каралган Министрлыкка тапшырыла торган мәгълүматның закон нигезендә дөрес булмавы һәм вакытында тапшырылмавы өчен җаваплы.

### 4. Гомуми нигезләмәләр

4.1. Яклар арасындагы бәхәсләр сөйләшүләр юлы белән, ә килешүгә ирешмәгәндә, суд тәртибендә хәл ителә.

4.2. Әлеге Килешүне үзгәртү Якларның инициативасы буенча әлеге Килешүгә аның аерылгысыз өлеше булган өстәмәләр рәвешендә язма рәвештә башкарыла, аларга Якларның вәкаләтле затлары кул куя.

4.3. Килешү Яклар тарафыннан имзаланганнан соң үз көченә керә һәм Яклар үз йөкләмәләрен тулысынча үтәгәнче гамәлдә була.

4.4. Әлеге Килешү бер үк юридик көчкә ия өч экземплярда төзелде, ике экземпляр Министрлыкка, берсе Алучыга бирелә.

**5. Якларның түләү реквизитыы**

| **Министрлык** | **Алучы** |
|---|---|
| Министрлыктан:<br>**Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы**420107, Казанш., Петербург ур.,12<br>ИНН 1655043416, КПП 165501001<br>ОКПО 57226209<br>Банк: РОССИЯ БАНКЫНЫҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ БАНКЫ БҮЛЕКЧӘСЕ // Татарстан Республикасы буенча УФК Казан ш.<br>БИК 019205400<br>р/с 03221643920000001100<br>(л/с ЛБ007190001-АпММол) | **Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты**<br>422000,Арча ш.,Совет мәйданы, 12<br>ИНН 1609009516 КПП 160901001<br>Р/сч 03100643000000011100<br>Банк : РОССИЯ БАНКЫНЫҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ БАНКЫ БҮЛЕКЧӘСЕ // Татарстан Республикасы буенча УФК Казан ш.<br>Кор.счет 40102810445370000079<br>БИК 019205400 ОГРН 1061685000024<br>ОКПО 93078288 ОКТМО 92612151 |

| | |
|---|---|
| Министр | Татарстан Республикасы<br>Арча муниципаль районы<br>Башкарма комитеты җитәкчесе |
| ____________________ В.А.Леонов | ____________________<br>Р.М.Гатиятов |
| имза | имза |
| М.У. | М.У. |

ПРОКУРАТУРА РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ПРОКУРАТУРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**ПРОКУРАТУРА**
**АРСКОГО РАЙОНА**
Галактионова ул., 1, Арск, 422000

329721 344309

Руководителю исполнительного комитета Арского муниципального района Республики Татарстан

Гатиятову Р.М.

15.03.2023 №01-01-2023/204-23-20920009

На № 914 от 03.03.2023

Сообщаю, что прокуратурой района рассмотрены проекты постановлений исполнительного комитета Арского муниципального района «О внесении изменений в постановление исполнительного комитета Арского муниципального района Республики Татарстан от 03.03.2020 №126 «Об установлении денежных выплат работникам - молодым специалистам физкультурных спортивных организаций, осуществляющих подготовку спортивного резерва в Арском муниципальном районе Республики Татарстан»; «О внесении изменений в постановление исполнительного комитета Арского муниципального района Республики Татарстан от 19.08.2021 №591 «О предоставлении мер социальной поддержки гражданам, имеющим детей, посещающих образовательные организации, реализующие образовательную программу дошкольного образования».

Содержащиеся в проектах постановлений нормы достаточны для достижения цели правового регулирования. Правила юридической техники соблюдены. Проекты постановлений не содержат коррупциогенных факторов. Нарушений федерального и республиканского законодательства не выявлено.

Замечаний по рассмотренным проектам НПА не имеется.

Прокурор района

старший советник юстиции Р.Р. Каримов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

Сертификат 008EC76DF51446A58217FE0A3A0CB23C90
Владелец **Каримов Ринат Раисович**
Действителен с 13.12.2022 по 07.03.2024

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
вх № 166
дата 20 03 2023 г

Р.Н. Юсупов, тел.: (84366) 3-21-80

Прокуратура Арского района Республики Татарстан
№ 01-01-2023/204-23-20920009